**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 гыйнварындагы 156 номерлы карары**

**2026 елда Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында**

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2026 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы «“Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү” дәүләт программасын раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 3 июнендәге 399 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы “Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 сентябрендәге 725 номерлы «2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»гы карары нигезендә:

**1. Карар бирәм:**

1.1. расларга:

1.1.1. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта);

1.1.2. 2026 елга Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм тәэмин итү планын һәм гомуми финанслау күләмен (2 номерлы кушымта);

1.1.3. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (3 номерлы кушымта);

1.1.4. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составын (4 номерлы кушымта);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (Д.И.Хвостиков), Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.2.1. беренче чиратта, авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру:

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән, физик һәм (яки) психик үсешләрендә җитешсезлекләре булган, үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә сәләтле балалар;

- бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә пособие алучы гаиләләрдән булган 17 яшькә кадәрге балалар;

- социаль яктан куркыныч хәлдә калган гаиләләрдә яшәүче балалар;

- качаклар һәм мәҗбүри күчеп китүчеләр, кораллы һәм милләтара низаглар, экологик һәм техноген һәлакәтләр, стихияле бәла-каза корбаннары гаиләләреннән булган балалар;

- махсус шартларда тәрбияләүгә, укытуга мохтаҗ һәм махсус педагогик якын килү таләп ителәә торган, шул исәптән профилактик исәптә торучы девиант тәртипле (иҗтимагый яктан куркыныч) балалар;

- килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормышлары объектив рәвештә бозылган һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яки гаилә ярдәмендә җиңә алмаган балалар, экстремаль шартларда калган балалар;

- Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балалары;

1.2.2. балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру системасын саклап калу, балаларның ялын оештыруны үстерү буенча чаралар күрү;

1.2.3. балалар ялы оешмаларының эшчәнлеге;

1.2.4. балалар ялы оешмаларында әзерлек эшләренең барышын контрольдә тоту һәм, 2025 елның 15 июненнән дә соңга калмыйча, балалар ялы оешмаларын ачу;

1.2.5. коммерцияле булмаган балалар ялы оешмаларында территорияне, җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәүлек буе саклау;

1.2.6. балалар ялы оешмаларында һәм оештырылган ял урыннарында балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, террорчылыкка каршы һәм янгынга каршы куркынычсызлыкны, судагы куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик чаралар комплексын үткәрү;

1.2.7. мунча-кер юу комплексларын карап тотуга, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы һәм кешеләргә янгын турында хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерү буенча беренчел чараларның булу-булмавына һәм аларның төзеклегенә, шулай ук янгын чыккан очракта кылынасы гамәлләр турында персоналның белүенә аерым игътибар биреп, һәр сменаны ачар алдыннан, аларның санитария кагыйдәләренә, суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәтен, ял итүчеләрнең куркынычсызлыгын саклау шартларына һәм торышына туры килүен тикшерү максатыннан, балалар ялы оешмаларын комплекслы рәвештә тикшерүне оештыру;

1.2.8. балалар ялы оешмалары тарафыннан башкарыла торган эшчәнлекнең санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә, шулай ук тикшерү органнарының тиешле рөхсәтләре булган очракта балалар ялы оешмаларын ачу;

1.2.9. балалар ялы оешмалары тарафыннан санитария кагыйдәләрен үтәү һәм билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән лаборатор-инструменталь тикшеренүләр уздыру турында килешүләр төзү юлы белән санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар башкару;

1.2.10. ял оешмаларына кабул ителгән балаларның медицина документларында профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививка ясалуы турында, яшәү, тәрбия, уку урыны буенча йогышлы авырулар белән авыручы затлар белән элемтәләр булмау, туберкулинодиагностика, флюорография тикшеренүе (15 яшьлек яшүсмерләр) нәтиҗәләре, гельминтозларга һәм эчәк протозоозларына тикшерү, йогышлы тире авыруларына, шул исәптән педикулезга тикшерү турында мәгълүматлар булу;

1.2.11. нинди төрдә булуларына карамастан балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларына эшкә алынган хезмәткәрләрнең медицина кенәгәләрендә профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививка ясауның торышы турында белешмәләр, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы «Россия Федерациясе Хезмәт

кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләргә мәҗбүри башлангыч һәм даими медицина тикшерүләре үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне башкаруга, шулай ук аларны башкарганда мәҗбүри башлангыч һәм даими медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләр башкаруга медицина каршылыклары исемлеген раслау турында»гы әмерендә каралган медицина тикшерүе һәм тикшеренүләре нәтиҗәләре турында белешмәләр, шул исәптән ризык әзерләү блокларына эшкә керүче хезмәткәрләргә; эшчәнлекләре азык-төлек продуктлары һәм эчә торган суны җитештерү, саклау, илтү, сату белән бәйле хезмәткәрләргә; суүткәргеч корылмаларны эксплуатацияләүне башкаручы затларга бактериаль һәм вируслы этиологияле эчәк инфекцияләрен кузгатучыларны билгеләү максатыннан лаборатор тикшерүләр үткәрү турында белешмәләр булу;

1.2.12. урман-техник чаралар үткәрү (дератизациягә һәм талпанга каршы эшкәртүгә кадәр һәм бөтен җәйге сәламәтләндерү кампаниясе дәвамында кирәк булган саен балалар ялы оешмалары территориясендә агачларның, куакларның тәбәнәк һәм коры ботакларын кисү, яшь үсентеләрне кисү, үлән чабу, чыбык-чабык һәм чүп-чар чыгару, балалар ялы оешмалары тирәсендә 500 метр радиуста чыбык-чабык һәм чүп-чар чыгару);

1.2.13. балалар ялы оешмалары тирәсендә 500 метр радиуста, балалар ялы оешмалары ачылганчы һәм аларны консервацияләгәнче, 10-14 көн алдан, шулай ук сменалар арасында барлык корылмаларда, шул исәптән файдаланылмый торганнарында, ачык территорияләрдә дератизация эшкәртүләре үткәрү;

1.2.14. балалар ялы оешмаларын ачканчы, 14 көн алдан, шулай ук, энтомологик күрсәткечләр булганда, сменалар арасында әлеге оешма территорияләрен һәм алар тирәсендә 50 метрлы зонаны талпаннан эшкәртү;

1.2.15. балалар ялы оешмаларын ачу алдыннан талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатыннан акарицидалар белән эшкәртүнең нәтиҗәлелеген тикшерү (файдаланыла торган препаратка карап, эшкәрткәннән соң 3-5 нче көндә), шулай ук билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән учреждениеләр белән килешүләр төзү юлы белән дератизация эшләренең сыйфатын тикшерү (үткәрелгән дератизациядән соң 10-14 көн узгач);

1.2.16. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (М.А.Патяшина), Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсендәге Казан шәһәре буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик

эш бүлеге (Р.В.Емекеев) белән килештереп, балалар ялы оешмалары җитәкчеләрен һәм педагогик составын билгеләнгән тәртиптә янгын-техник минимумы һәм гигиеник әзерлек программалары буенча барлык хезмәткәрләрне укытуны уртак рәвештә оештыру;

1.2.17. 2026 елның 1 июненнән 30 августына кадәр йорт яны территорияләрендә мәгариф оешмалары, яшүсмерләр клублары һәм яшьләр үзәкләре базасында балалар ял итү мәйданчыклары эше;

1.2.18. ял оешмаларына эшкә урнашкан затларга карата, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331, 351.1 статьялары таләпләре нигезендә, хөкем ителү һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булу яки билгеле бер җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвен туктату буенча беренчел тикшерүләр уздыру;

1.2.19. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 сентябрендәге 1527 номерлы «Балалар төркемен автобуслар белән оешкан төстә йөртү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган Балалар төркемен оешкан төстә автобуслар белән йөртүне оештыру кагыйдәләре нигезендә балаларны йөртүне оештыру;

1.2.20. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга субсидияләрне файдалану һәм тоту нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләренә ирешү турында хисапны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына үз вакытында тапшыру;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (Д.И.Хвостиков), Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов):

1.3.1. ведомство карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләр өчен, авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен стационар лагерьларда сменалар, шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль бирем формалаштыруны һәм билгеләнгән муниципаль биремгә керем һәм чыгым сметаларын раслауны тәэмин итәргә;

1.3.2. әлеге муниципаль биремне Татарстан Республикасы бюджетыннан, Казан шәһәре бюджетыннан бүлеп бирелгән субсидияләр, ата-аналар акчалары һәм гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар хисабына финанслар белән тәэмин итәргә;

1.3.3. балаларның ялын оештыру буенча муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга бюджет классификациясенең билгеләнгән кодлары киселешендә

нигезләп бүлүне Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә 2026 елның 24 апрелена кадәр бирүне тәэмин итәргә;

1.3.4. 2026 елга Казан шәһәрендәге балаларның һәм яшьләрнең ял программасын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.4.1. ведомство карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләр белән Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 4 маендагы 1269 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән, мәктәп каршындагы лагерьларны оештыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турындагы» карары нигезендә көндезге мәктәп яны лагерьларында, хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыруга билгеләнгән күләм чикләрендә максатчан субсидия бирү турында килешүләр төзергә;

1.4.2. көндезге мәктәп яны лагерьларында, хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыруны Татарстан Республикасы бюджетыннан, Казан шәһәре бюджетыннан бүлеп бирелгән субсидияләр, ата-аналар акчалары һәм гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар хисабына финанс белән тәэмин итәргә;

1.4.3. балаларның ялын оештыру буенча ведомство карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләрне финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга бюджет классификациясенең билгеләнгән кодлары киселешендә нигезләп бүлүне Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә 2026 елның 24 апрелена кадәр бирүне тәэмин итәргә;

1.4.4. 2026 елга Казан шәһәрендәге балаларның һәм яшьләрнең ял программасын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.5.1. каникул чорында балаларга өстәмә белем бирә торган барлык учреждениеләрнең эшен;

1.5.2. өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан оештырылган көндезге мәктәп яны лагерьларында балаларга өстәмә белем бирә торган вакытлы (кыска сроклы) берләшмәләр (түгәрәкләр, секцияләр, үзәкләр һ.б.) оештыруны;

1.5.3. мәктәп янындагы көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыруны;

1.5.4. көндезге мәктәп яны лагерьларында Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан граждannar гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) граждannar гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларының ялын оештыруны;

1.5.5. балалар иҗаты шәһәр үзәкләре базасында балаларның ялын оештыру буенча эшкә җибәрелә торган педагогик кадрларны әзерләүне;

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (Д.И.Хвостиков) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.6.1. балалар ялы оешмаларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны;

1.6.2. авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын палатка тибындагы лагерьда махсуслаштырылган сменаларда, балалар ялы оешмаларында сәламәтләндерү сменаларында оештыруны;

1.6.3. балалар ялы оешмаларында Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан граждannar гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) граждannar гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларының ялын оештыруны;

1.6.4. башка учреждениеләрдә оештырылган көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыруны;

1.7. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (А.Р.Заһидуллина) балалар ялы оешмаларында күчмә китапханәләр эшен оештырырга;

1.8. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.8.1. балалар ялы оешмаларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда Казан шәһәренең ведомство карамагындагы балалар спорт мәктәпләрендә укучыларның ялын оештыруны;

1.8.2. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус

хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларының – Казан шәһәренең ведомство карамагындагы балалар спорт мәктәпләре укучыларының ялын балалар ялы оешмаларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда оештыруны;

1.8.3. җәйге чорда спорт комплекслары, стадионнар, балалар һәм яшьләр ялы спорт оешмалары тарафыннан балалар һәм яшьләр катнашында спорт-массакүләм һәм туристлык чараларын оештыру эшен координацияләүне;

1.8.4. балалар ялы оешмаларында массакүләм спорт-сәламәтләндерү чараларын үткәрүне;

1.9. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (Д.И.Хвостиков) Казан шәһәренең «“Ял” балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча шәһәр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе (К.А.Крайнов) белән берлектә:

1.9.1. түбәндәге категорияләргә караган балаларның ялын оештыруны тәэмин итәргә:

- бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле пособие алучы гаиләләрдәге 17 яшькә кадәрге балалар; гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, үз-үзенә хезмәт күрсәтә ала торган мәктәп яшендәге инвалид балалар, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар; качаклар һәм мәҗбүри күчеп кайтырга мәҗбүр булган кешеләр гаиләләреннән булган балалар, коралллы һәм милләтара низаглар, экологик һәм техноген катастрофалар, стихияле бәла-казалар корбаннары; социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр;

- Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балалары;

- өстәмә гомуми белем бирү, гомуми белем бирү һәм беренчел һөнәри әзерлек программаларын үзләштерүче, иҗади яктан сәләтле һәм социаль яктан актив балалар, укучылар, профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда спорт әзерлеге узучы балалар;

1.9.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә ял оештыруны тәэмин итәргә:

- социаль яктан куркыныч хәлдә калган гаиләләрдәге балаларның;
- экстремаль шартларда калган балаларның;
- үз-үзен тотышында тайпылышлар булган балаларның;

1.9.3. Казан шәһәре Башкарма комитеты сменалар оештыручы булып торган балалар ялы оешмалары эшчәнлеген координацияләү;

1.9.4. балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны яхшырту турында мәгълүмат җыюны оештырырга һәм әлеге тәкъдимнәрне карап тикшерү өчен Казан шәһәренең балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру буенча ведомствоара комиссиягә бирергә;

1.9.5. оешма турында мәгълүмат җыю, сәламәтләндерү кампаниясен оештыру һәм халыкка оешкан төстә ял итүнең балалар һәм яшьләр сәламәтлегенә уңай йогынты ясавы турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерү максатыннан, массакүләм мәгълүмат чараларын һәм башка кызыксынучы ведомство вәкилләрен дә җәлеп итеп, балалар ялы оешмаларына баруларны даими рәвештә оештыру;

1.9.6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына әлеге хисапларны тапшыруның билгеләнгән срокларына кадәр өч эш көне кала, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга 2026 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүдә каралган хисапны бирүне тәэмин итәргә;

1.10. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының эшләр идарәсенә (Л.Р.Гафаров) Казан шәһәре балаларының һәм яшьләренең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру буенча ведомствоара комиссияне, әлеге карар белән үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен, балалар һәм яшьләр ялы оешмаларына баруларын оештыру максатыннан транспорт чарасы белән тәэмин итәргә;

1.11. Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсенә (С.Х.Чанкин) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.11.1. балалар ялы оешмаларында һәм массакүләм ял итү урыннарында оештырылган коену урыннарын, килешү нигезендә гаризалар буенча су төбен тикшереп һәм су объектлары акваторияләре төбен чистартып, техник тикшереп чыгу;

1.11.2. әзерлек эшләре һәм ял итү чорында балалар ялы оешмаларында һәм күпләп ял итү урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешенә күзәтчелек итү;

1.12. балалар ялы оешмаларындагы персоналга хезмәт хакы, башка финанслау чыганакларын җәлеп итү гамәлдәге законнарга каршы килмәгән очракта, әлеге чыганаклар хисабына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнарының гамәлдәге нормативлары чикләрендә түләнә дип билгеләргә;

1.13. әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә;

1.14. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. балансында шәһәр яны ял лагерьлары булган һәм балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнаша торган, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга бюджет акчалары алучы, барлык милек формасындагы предприятиеләргә, оешмаларга, берләшмәләргә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.1.1. балалар ялы оешмаларының эшчәнлеген;

2.1.2. Казан шәһәренең «“Ял” балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча шәһәр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе (К.А.Крайнов) тарафыннан үткәрелә торган вожатыйлар әзерләү курсларында укытуны оештыру;

2.1.3. балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга кергән акчаларны максатчан файдалану;

2.1.4. түбәндәгеләрне Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына тапшыру:

2.1.4.1. 2026 елның 25 апреленә кадәр – барлык төрдәге балалар ялы оешмаларын ачуның типлаштырылган формадагы графикларын;

2.1.4.2. 2026 елның маеннан 2027 елның гыйнварына кадәрге чорда һәр айның 5 нче көненә кадәр – балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча оператив, 20 нче көненә кадәр – айлык йомгаклау финанс хисабын;

2.1.4.3. 2026 елның июненнән 2027 елның гыйнварына кадәрге чорда һәр айның 1 нче көненә кадәр – акчаларны балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга файдалану турында хисапны;

2.1.4.4. 2026 елның 25 августына кадәр – үткәрелгән чаралар турында фото- һәм видеоматериаллар булган иҗади хисапларны;

2.1.5. заказчы һәм тәэмин итүче тарафыннан имзаланганнан соң, керү графигы буенча муниципаль контрактны үтәү;

2.2. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсендәге Казан шәһәре буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә (Р.В.Емекеев) балалар ялы оешмаларында янгын куркынычсызлыгы чараларының үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

2.3. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) түләү алмыйча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.3.1. балаларны балалар ялы оешмасына оешкан төстә алып бара һәм алып кайта торган транспорт чараларын Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсендәге Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенең патруль автомобильләре озата баруны;

2.3.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (И.А.Ризванов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре белән берлектә балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү һәм каникул чорында балаларның урамда хәвефсез йөрүе өчен шартлар тудыру буенча чаралар күрүне;

2.3.3 урман-парк зоналарына, көндезге белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган лагерьлар урнашкан урыннарга һәм барлык төр милек формаларындагы шәһәр яны лагерьларына автотранспорт керүне чикләүне, җәмәгать тәртибен тәэмин итү өчен әлеге зоналарга патрульлек итүне көчәйтүне;

2.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә (И.М.Әхмәдиев):

2.4.1. балалар ялы оешмаларын гамәлгә куючылар гаризалары буенча контракт нигезендә медицина кадрлары белән тәэмин итүне оештырырга;

2.4.2. балалар ялы оешмаларында квалификацияле медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.4.3. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләргә мәҗбүри беренчел һәм даими медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне башкаруга, шулай ук аларны башкарганда мәҗбүри беренчел һәм даими медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләрне башкаруга медицина каршылыклары исемлеген раслау турында»гы әмере таләпләре нигезендә Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне оештыруга бүлеп бирелә торган

акчалар хисабына, түләү алмыйча, ял оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналны сезонлы тикшерү эшен оештырырга;

2.4.4. сәламәтләндерү сезоны башланыр алдыннан (шулай ук сәламәтләндерү сезоны барышында эшкә алынганда) Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм сәламәтләнүен оештыруга бүленә торган чаралар хисабына, түләү алмыйча, бактериаль һәм вируслы этиологияле эчәклек инфекцияләрен китереп чыгаручыларны билгеләү максатыннан ризык әзерләү блокларына эшкә килүче хезмәткәрләрнең, эшчәнлеге азык-төлек һәм су җитештерү, саклау, илтү, сату белән бәйле, балалар ялы оешмаларында (шул исәптән көндезге) суүткәргеч корылмаларны эксплуатацияләүче хезмәткәрләрнең бер тапкыр лаборатор тикшерү үтүен тәэмин итәргә;

2.4.5. балалар ялы оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналга сезонлы тикшерүләр уздыру кысаларында бушлай флюорографик тикшерү уздыруны тәэмин итәргә;

2.4.6. көндезге белем бирү учреждениеләре тарафыннан оештырылган лагерьларда территориаль принцип буенча дәвалау-профилактика учреждениеләренең медицина хезмәткәрләре көче белән балаларга медицина хезмәте күрсәтүне оештырырга;

2.5. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) 2026 елгы сәламәтләндерү кампаниясен әзерләү һәм уздыру барышын, балалар ялы оешмаларының балаларны тәрбияләү, үстерү һәм аларның сәламәтлеген ныгыту буенча уңай эш тәҗрибәсен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка **йөкләргә.**

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 22 гыйнварындагы
156 номерлы карары белән
расланган 1 номерлы кушымта

**Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Казан шәһәре Башкарма комитеты структур бүлекчәләренең һәм муниципаль оешмаларның Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру буенча эш итү механизмын, аларның Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруда катнашучы муниципаль, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә кысаларында, балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү дигәндә, балаларны тәрбияләүгә, аларның иҗади потенциалын үстерүгә, сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга, балаларда авыруларны профилактикалауга, аларның физик культура, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүенә, балаларда сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруга, санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология таләпләрен һәм балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итү таләпләрен үтәп, уңайлы әйләнә-тирә мохиттә аларның туклану һәм тормыш эшчәнлеге режимын үтәүгә юнәлдерелгән, өлешчә яисә тулысынча Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына финанслана торган чаралар җыелмасы аңлашыла.

## II. Балалар һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү формалары

2.1. Казан шәһәрендә балалар һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү түбәндәге формаларда оештырыла:

шәһәр яны ял һәм сәламәтләндерү лагерендагы смена;

шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена;

палатка тибындагы лагерьда смена;

белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьда көндезге смена;

хезмәт һәм ял лагеренда смена;

2.2. Шәһәр яны ял һәм сәламәтләндерү лагеренда смена – каникул чорында балалар белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы, анда укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе стационар базада була. Җәйге каникулларда смена кимендә – 21 көн, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда кимендә 7 көн булырга тиеш.

2.3. Шәһәр яны ял лагеренда профильле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена – билгеле бер эшчәнлек өлкәсендәге уңышларны исәпкә алып яисә балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүгә юнәлтелгән сменаларның тематик программасы юнәлешен исәпкә алып, балалар мәнфәгатьләрен үстерүне тәэмин итү максатыннан алып барыла торган иҗади яктан сәләтле һәм социаль актив балалар белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Җәйге каникулларда смена кимендә 18 көн дәвам итә. Балаларга өстәмә белем бирүнең профильле һәм тематик программалары үзенчәлекләрен исәпкә алып, 7 көннән 18 көнгә кадәр дәвам итә торган профильле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена оештыру мөмкинлеге бар. Көзге, кышкы һәм язгы каникулларда смена 7 көн дәвам итә.

2.4. Палатка тибындагы лагерьда смена – балаларның иҗади потенциалын үстерү, табигать шартларында булуның гамәли күнекмәләрен үзләштерү, физик культура, туризм, туган якны өйрәнү, укыту-тикшеренү һәм башка эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнү максатыннан балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү, сәламәтлеген ныгыту формасы. Палатка тибындагы лагерьда тәкъдим ителә торган смена дәвамлылыгы – 5 көннән 21 көнгә кадәр. Палатка тибындагы лагерьда 7 көннән артык эшли торган сменалар оештырганда, балаларны юындыру оештырылырга тиеш.

2.5. Белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьда көндезге смена – белем бирү оешмаларында укучылар белән каникуллар чорында күбесенчә белем бирү оешмасы базасында үткәрелә торган, укучылар көндезге вакытта була һәм санитария законнары таләпләре нигезендә, эшләү дәвамлылыгына бәйле рәвештә, көн буена аларның туклануы мәҗбүри оештырыла торган ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменаның

дәвамлылыгы каникулларның озынлыгыннан чыгып билгеләнә: җәйге каникул чорында – кимендә 21 календарь көн; көз, кыш һәм яз көннәрендә кимендә 7 көн тәшкил итә.

2.6. Хезмәт һәм ял лагеренда смена – җәмгыятькә файдалы хезмәт оештырылган, күбесенчә гомуми белем бирү оешмалары базасында каникуллар вакытында үткәрелә торган, көндезге һәм туклану белән тәэмин итү булдырылган ял итү һәм сәламәтләндерү формасы. Сменаның озынлыгы – 8 көн.

2.7. Лагерьларда отрядлар балаларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып туплана. Отрядларда балалар саны лагерьларны оештыруга, карап тотуга, эш режимын урнаштыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә билгеләнә.

## III. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар

3.1. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар булып бирелгән вәкаләтләр чигендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Физик культура һәм спорт комитеты тора.

3.2. Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру сменаларында катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы 6,5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яисә вакытлыча яшәүче 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп), иҗади яктан сәләтле һәм социаль актив, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучы балалар һәм спорт әзерлеге узучы балалар;

авыр тормыш хәлендә калган балалар, шул исәптән:

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләр, опекунлыкка һәм тәрбиягә алынган гаиләләрдә тәрбияләнүче 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) ятим балалар;

үз-үзенә хезмәт күрсәтә алучы инвалид балалар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) балалар;

балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүче социаль реабилитациягә мохтаҗ затлар;

социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге 7 яшьтән 17 яшькә

кадәрге (аны да кертеп) балалар;

девиант тәртипле укучылар өчен белем бирү оешмаларында булган (профилактик исәптә торучы) 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) балалар;

килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормышлары объектив рәвештә бозылган һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль яки гаилә ярдәмендә җиңә алмаган 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) балалар;

бала туугa һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә пособие алучы гаиләләрдән булган 17 яшькә кадәрге балалар;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балалары.

3.3. Казан шәһәре Башкарма комитеты билгеләнгән тәртиптә бюджеттан финанслана торган түбәндәге сменаларны оештыручы булып тора:

6,5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар өчен белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьлардагы, хезмәт һәм ял лагерьларындагы сменалар;

иҗади яктан сәләтле һәм социаль актив, өстәмә белем бирү программаларын үзләштерүче 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) укучы балалар өчен шәһәр читендәге ял лагерьларында профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балалары өчен профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар;

профилактик исәптә торучы балалар өчен палатка тибындагы лагерьларда сменалар;

авыр тормыш хәлендә калган 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (аны да кертеп) балалар өчен ял һәм сәламәтләндерү буенча шәһәр яны лагерендагы сменалар.

## IV. Казан шәһәрендә балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруны финанслау тәртибе

4.1. Казан шәһәрендә балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруны финанслау, законнарга нигезләнеп, түбәндәге чыганаклардан башкарыла:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

Казан шәһәре бюджеты акчалары;

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) акчалары.

4.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (99% – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына, 1% – Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына) Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары нигезендә Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләме чикләрендә башкарыла. Әлеге пунктта күрсәтелгән тиешле финанс елына норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4.3. Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга тиешле финанс елына дәүләт хезмәте күләме нормативлары балалар һәм яшьләр ялы һәм аларны сәламәтләндерү кампанияләрендә катнашучылар һәм смена оештыручылар киселешендә ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга дәүләт хезмәтләре күләме нормативларын исәпләү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасында халыкның социаль хезмәтләр (инфраструктура) белән тәэмин ителешенең социаль гарантияләре дәрәҗәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы халкының демографик үзенчәлекләрен, структурасын һәм факттагы мохтаҗлык дәрәҗәсен исәпкә алып башкарыла.

4.4. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның, ятим балалар, профилактик исәптә торучы балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларның, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының)

балаларының ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслана.

4.5. Татарстан Республикасы бюджеты хисабына балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруны финанслауда катнашу өлеше:

профилактик исәптә торучы балалар өчен палата тибындагы лагерьларда профильле сменаларда, гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен хезмәт һәм ял лагерьларында, авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен ял итү оешмаларында; Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гаиләләре (гаилә әгъзалары) балалары өчен профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда тиешле финанс елында балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга норматив чыгымнарның 100 проценты;

шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда, белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьлардагы сменаларда тиешле финанс елында балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру өчен норматив чыгымнарның 85 проценты.

## V. Балаларның һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләве күләмен билгеләү тәртибе

5.1. Балаларның һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләвенең күләме ял оешмалары тарафыннан билгеләнә. Балаларның һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләвенең минималь күләме тиешле финанс елына расланган балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга тотылган норматив чыгымнарның 15 проценты күләмендә билгеләнә. Әгәр норматив чыгымнар күрсәтелгән хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез булган чыгымнарны капламаса, юлламаның факттагы бәясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә, әмма ул дәүләт һәм муниципаль ял оешмалары өчен юлламаның факттагы бәясенең 50 процентыннан артмаска тиеш.

5.2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан лагерьларда балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү өчен ата-аналар түләве түбәндәге очракларда алынмый:

хезмәт һәм ял лагерьларында булган гомуми белем бирү оешмалары укучыларыннан;

авыр тормыш хәлендә калган балалардан;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларыннан.

## VI. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда смена оештыру тәртибе

6.1. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьга ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә белем бирү оешмаларында укучылар җибәрелә. Ата-аналарның гаризасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча бала укыган белем бирү оешмасына тапшырыла.

6.2. Белем бирү оешмасы ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә балаларның исемлеген төзи һәм аны Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә тапшыра. Исемлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны;

бала укый торган белем бирү оешмасының атамасы;

бала укый торган сыйныф.

6.3. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларына юллама алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, өстәмә

рәвештә категорияне раслаучы документлар тапшырыла:

баланың атасының яисә анасының (законлы вәкиленең) махсус хәрби операция уздыруда катнашуын раслый торган документлар (белешмәләр);

махсус хәрби операция уздыруда катнашучы яки катнашкан гражданин баланың 18 яшькә кадәр законлы вәкиле (ата-анасыннан тыш) булуын законнар нигезендә раслый торган документлар.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар исемлекләре нигезендә балаларның җыелма исемлеген һәм аларның белем бирү оешмасы оештырган көндезге лагерьларда ялын оештыру планын төзи.

6.4. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге лагерьларда балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру планы тиешле финанс елына Казан шәһәре Башкарма комитетына җиткерелгән көндезге лагерьларда балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга хезмәтләр күләме нормативлары чикләрендә формалаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең белем бирү оешмалары базасында лагерьлар оештырылачак мәгариф бүлекләре исемнәре;

Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгариф бүлекләре буенча белем бирү оешмалары тарафыннан оештырыла торган лагерьлар саны;

Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгариф бүлекләре буенча лагерьларда оештырылган урыннар саны.

6.5. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге лагерьларда балаларның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны оештыру планы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

## VII. Хезмәт һәм ял лагерьларында смена оештыру тәртибе

7.1. Хезмәт һәм ял лагерьларына җәмгыятькә файдалы хезмәткә җәлеп итү максатыннан белем бирү оешмалары укучылары җибәрелә.

7.2. Белем бирү оешмасы хезмәт һәм ял лагерьларына җибәрелә торган балалар исемлеген төзи һәм аны Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә тапшыра. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укый торган белем бирү оешмасының атамасы;

бала укый торган сыйныф.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белем бирү оешмаларында укучы балаларның исемлекләре буенча аларның хезмәт һәм ял лагерьларында ял итүен оештыру планы нигезендә балаларның җыелма исемлеген төзи.

7.3. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне аларны туклandыруны да булдырып оештыру планы Казан шәһәре Башкарма комитетына тиешле финанс елына җиткерелгән лагерьларда балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга хезмәтләр күләмнәре нормативлары чикләрендә формалаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак белем бирү оешмалары исемнәре;

белем бирү оешмалары буенча хезмәт һәм ял лагерьларында җәмгыятькә файдалы хезмәткә җәлеп ителгән кешеләр саны.

7.4. Хезмәт һәм ял лагерьларын оештыру планы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

## VIII. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру тәртибе

8.1. Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан җаваплы башкаручы итеп билгеләнгән Казан шәһәренең «“Ял” балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре белән берлектә авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен юлламалар бирүгә ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан бирелгән гаризаларны кабул итә.

8.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ай саен Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган балалар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүче балаларның һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балаларның реестрын тапшыра.

8.3. Казан шәһәренең «“Ял” балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе, дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны кулланып, бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле айлык пособие алучы гаиләләрдән 17 яшькә кадәрге балаларның гомуми исемлеген формалаштыра.

8.4. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру планы Казан шәһәренең «“Ял” балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан формалаштырыла һәм анда лагерьларның исемнәре, әлеге категориядәге балалар җибәрелә торган лагерьлардагы урыннар һәм сменалар саны, закон нигезендә үткәрелә торган конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча сатып алына торган шәһәр яны лагерьларына юлламалар саны турында мәгълүмат бирелә.

8.5. Балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру планы Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## IX. Шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру тәртибе

9.1. Әлеге бүлек балалар өчен профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге (оборона-спорт, туристлык, экологик-биологик, иҗади, тарихи-патриотик, техник, туган якны өйрәнү һәм башкалар) сменалар эшчәнлеген җайга сала.

9.2. Профильле лагерь эшчәнлегенең предметы булып профильле лагерь юнәлешенә туры килә торган эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә казанышлары булган иҗади яктан сәләтле яисә социаль актив балаларның үсешен тәэмин итү, шулай ук балаларның ялына һәм аларны сәламәтләндерүгә юнәлтелгән чаралар оештыру һәм үткәрү тора. Профильле лагерьда балаларның эшчәнлеге, балаларның белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсенә, профильле сменаның тәрбия һәм белем бирү бурычларына бәйле рәвештә, бер яшьтәге һәм төрле яшьтәге балалар берләшмәләрендә (отрядлар, төркемнәр, командалар) оештырыла.

9.3. Тематик лагерь сменалары программалары юнәлешен (тематикасын) (оборона-спорт, туристлык, экологик-биологик, иҗади, тарихи-патриотик, техник, туган якны өйрәнү һәм башкалар) исәпкә алып, балаларның һәрьяклы мәнфәгатьләрен үстерүне тәэмин итү, шулай ук балаларның ялына һәм аларны сәламәтләндерүгә юнәлтелгән чараларны оештыру һәм үткәрү тематик лагерьның эшчәнлек предметы булып тора. Тематик лагерьда балаларның эшчәнлеге, тематик лагерь сменалары программаларының юнәлешенә (тематикасына), балалар мәнфәгатьләренә, тематик лагерьның тәрбия һәм белем бирү бурычларына бәйле рәвештә, бер яшьтәге һәм төрле яшьтәге балалар берләшмәләрендә (отрядларда, төркемнәрдә, командаларда) оештырыла.

9.4. Профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар оештыру планы ял оешмасы тарафыннан раслана.

9.5. Шәһәр яны ял лагерьларының профильле сменаларында һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларында катнашу өчен иҗади яктан сәләтле һәм социаль актив балалар, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар, спорт әзерлеге узучы балалар ата-аналарның берсеннән (яки законлы вәкилләреннән) гариза нигезендә җибәрелә.

9.6. Урнаштыру, җиһазлау, карап тоту һәм оештыру шартлары санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм гигиена нормативларына, янгын һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килергә тиеш.

9.7. Ял оешмасы катнашучыларның җыелма исемлеген формалаштыра. Анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (балигъ булмаган гражданнар өчен);

катнашучының туган көне һәм туган урыны, җенесе;

яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар.

9.8. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләргә караган һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренең (гаилә әгъзаларының) балаларына юллама алу өчен гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, өстәмә рәвештә категорияне раслаучы документлар тапшырыла:

баланың атасының яисә анасының (законлы вәкиленең) махсус хәрби операция уздыруда катнашуын раслый торган документлар (белешмәләр);

махсус хәрби операция уздыруда катнашучы яки катнашкан гражданин 18 яшькә кадәр баланың законлы вәкиле (ата-анасыннан тыш) булуын законнар нигезендә раслый торган документлар.

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2026 елның
22 гыйнварындагы
156 номерлы карары белән расланган
2 номерлы кушымта

**2026 елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм тәэмин итү планы**
**һәм финанслауның гомуми күләме**

## I. 2026 елга Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планы

| Балалар категорияләре атамалары | Сменаны оештыручылар | Балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру формасы | Балалар саны |
|---|---|---|---|
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Хезмәт һәм ял лагеренда 18 көнлек смена | 3 430 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | Белем бирү оешмалары тарафыннан ел дәвамында каникуллар чорында оештырылган 21 көнлек көндезге лагерь сменасы | 18 000 |
